ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

## Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклауның аерым мәсьәләләре турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2026 елның 22 июлендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) нигезендә халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән (алга таба – гадәттән тыш хәлләр) яклау өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының вәкаләтләрен билгели, шулай ук халыкны һәм территорияләрне муниципальара һәм региональ характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклауның аерым мәсьәләләрен җайга сала.

2 статья. **Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу**

Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу Федераль закон, башка федераль законнар һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

3 статья. **Әлеге Законда кулланыла торган төшенчәләр**

Әлеге Законда кулланыла торган төшенчәләр Федераль законда билгеләнгән мәгънәләрендә кулланыла.

4 статья. **Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләре**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы халыкны һәм территорияләрне муниципальара һәм региональ характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә Татарстан Республикасы законнарын кабул итә, аларның үтәлешен тикшереп тора, Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

5 статья. **Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә Татарстан Республикасы Рәисе вәкаләтләре**

Татарстан Республикасы Рәисе:

1) килеп чыккан гадәттән тыш хәлләрне региональ яисә муниципальара характердагы гадәттән тыш хәлләргә кертү турында карарлар кабул итә, Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль ярдәмче системасының тиешле идарә органнары һәм көчләре өчен югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимын кертә;

2) Федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә чара күрүнең региональ дәрәҗәсен билгели;

3) Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясен җитәкли.

6 статья. **Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты:

1) федераль законнар, әлеге Закон нигезендә халыкны һәм территорияләрне муниципальара һәм региональ характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә норматив хокукый актлар кабул итә;

2) халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өчен кирәкле көчләрне һәм чараларны әзерләүне һәм аларны әзерлектә тотуны, шулай ук гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә халыкны әзерләүне гамәлгә ашыра;

3) региональ һәм муниципальара характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы булганда яисә алар килеп чыкканда эвакуация чараларын үткәрүне тәэмин итә;

4) гадәттән тыш хәлләр турында халыкка мәгълүмат бирүне гамәлгә ашыра;

5) муниципальара һәм региональ характердагы гадәттән тыш хәлләрдә һәлакәттән коткару эшләрен һәм башка кичектергесез эшләрне оештыра һәм үткәрә, шулай ук аларны үткәргәндә җәмәгать тәртибен саклый; үз көчләре һәм чаралары җитәрлек булмаганда Россия Федерациясе Хөкүмәтенә ярдәм күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итә;

6) Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге чараларны финанслауны гамәлгә ашыра;

7) муниципальара һәм региональ характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен финанс ресурслары һәм матди ресурслар резервларын булдыра;

8) муниципальара һәм региональ характердагы гадәттән тыш хәлләрдә оешмаларның тотрыклы эшчәнлегенә ярдәм итә;

9) халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге бурычларны хәл итүгә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органына халыкка гадәттән тыш хәлләр турында вакытында хәбәр итү һәм мәгълүмат бирү, гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә халыкны әзерләү максатларында кешеләр күпләп җыелган урыннарда халыкка хәбәр итүнең һәм мәгълүмат бирүнең махсуслаштырылган техник чараларын урнаштыру өчен участоклар бирүдә һәм (яисә) мондый чараларны урнаштыруда, шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары продукциясен тарату өчен булган техник җайланмаларны бирүдә, эфир вакытын бүлеп бирүдә ярдәм күрсәтә;

10) гадәттән тыш хәлләр килеп чыккан очракларда Россия Федерациясе гражданнарына, чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга бер мәртәбә бирелә торган акчалата түләүләрне, бер мәртәбә бирелә торган акчалата түләүләрне гамәлгә ашыру очракларын, шулай ук әлеге түләүләр биреләчәк затлар даирәсен билгеләүне дә кертеп, гамәлгә ашыру турында карарлар кабул итә;

11) Татарстан Республикасы территориясендә «112» бердәм номеры буенча ашыгыч оператив хезмәтләр чакыруны тәэмин итү системасын булдыруны гамәлгә ашыра, аны эксплуатацияләүне һәм үстерүне тәэмин итә;

12) гадәттән тыш хәлләр турында халыкка хәбәр итү һәм мәгълүмат бирү системаларын булдыра һәм аларны даими әзерлек хәлендә тота;

13) халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә мәгълүмат җыюны һәм мондый мәгълүмат алмашуны гамәлгә ашыра, муниципальара һәм региональ характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы турында яисә аларның килеп чыгуы хакында халыкка вакытында, шул исәптән гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы турында яисә аларның килеп чыгуы хакында халыкка ашыгыч хәбәр итүнең комплекслы системасын кулланып, хәбәр итүне тәэмин итә;

14) халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә региональ дәүләт күзәтчелеге турында нигезләмәне, җирле үзидарә органнары тарафыннан халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга дәүләт күзәтчелеге тәртибен раслый;

15) Татарстан Республикасы территориясендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү гамәлләре планнарын эшли һәм раслый;

16) әлеге Законның 5 статьясындагы 1 пункты нигезендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы кертелгәндә гражданнар һәм оешмалар тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиешле тәртип кагыйдәләрен билгели;

17) Федераль законның 10 статьясындагы «а$^{2}$» пунктчасы нигезендә билгеләнгән тәртип кагыйдәләрен үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы территориясендәге гадәттән тыш хәлнең үзенчәлекләрен яисә аның килеп чыгу куркынычын исәпкә алып, кирәк булганда, Федераль законның

10 статьясындагы «а[1]» пунктчасы нигезендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы кертелгәндә гражданнар һәм оешмалар тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиешле өстәмә тәртип кагыйдәләрен билгели;

18) муниципальара һәм региональ характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм алардан килгән зыяннарны бетерү чараларын үткәрә, гадәттән тыш хәлләрдә кешеләрнең гомерен һәм сәламәтлеген саклап калуга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыра;

19) халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге бурычларны хәл итүгә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының территориаль органы, шулай ук территорияләрендә гадәттән тыш хәл килеп чыгарга мөмкин булган җирле үзидарә органнары һәм оешмалар белән килештереп, халыкка ашыгыч хәбәр итү зоналарының чикләрен билгели;

20) Татарстан Республикасы территориясендә су объектларында кече суднолардан файдалану кагыйдәләрен раслый;

21) Татарстан Республикасы территориясендә су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү кагыйдәләрен раслый;

22) эчәргә яраклы су һәм хуҗалык-көнкүреш сулары белән тәэмин итү чыганакларын резервлауны гамәлгә ашыра;

23) торак йортларга, фатирларга, Россия Федерациясе Торак кодексы белән билгеләнгән торак урыннарның башка төрләренә (алга таба – торак урыннар) килгән зыянны каплауны оештыру максатларында, кирәк булганда, Федераль закон, «Россия Федерациясендә иминият эшен оештыру турында» 1992 елның 27 ноябрендәге 4015-I номерлы Россия Федерациясе Законы һәм башка норматив хокукый актлар нигезләмәләренә таянып, ирекле иминләштерү механизмын кулланып, гражданнарның Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан торак урыннарына килгән зыянны каплауны оештыру программасын эшли, раслый һәм гамәлгә ашыра;

24) Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендәге 1 – 9, 11 – 13, 15, 18, 19, 22 һәм 24 пунктларында күрсәтелгән вәкаләтләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яисә ул вәкаләт биргән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы (органнары) тарафыннан гамәлгә ашырыла. Әлеге статьяның 1 өлешендәге 10, 14, 16, 17, 20, 21 һәм 23 пунктларында күрсәтелгән вәкаләтләр турыдан-туры Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

### 7 статья. **Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль ярдәмче системасы**

1. Татарстан Республикасында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү өчен гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү бердәм дәүләт системасының состав өлеше булган Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль ярдәмче системасы булдырыла. Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль ярдәмче системасының

идарә органнары һәм көчләре эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль ярдәмче системасы турында нигезләмә һәм аның эшчәнлеге тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

## 8 статья. **Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә региональ дәүләт күзәтчелеге**

Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә региональ дәүләт күзәтчелеге халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге бурычларны хәл итүгә махсус вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслый торган нигезләмәгә таянып гамәлгә ашырыла.

## 9 статья. **Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау чараларын финанс ягыннан һәм матди яктан тәэмин итү**

1. Региональ һәм муниципальара характердагы гадәттән тыш хәлләрне (урман янгыннары аркасында урманнарда килеп чыккан гадәттән тыш хәлләрдән тыш) кисәтү һәм алардан килгән зыяннарны бетерү буенча Федераль законда билгеләнгән чараларны финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасының бурыч йөкләмәсе булып тора.

2. Гадәттән тыш хәлләр килеп чыккан очракта ашыгыч рәвештә кирәкле чараларны җәлеп итү максатларында Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен алдан ук финанс ресурслары һәм матди ресурслар резервлары булдырыла.

Әлеге өлешнең беренче абзацында күрсәтелгән резервларны (резерв фондларын) булдыру һәм алардан файдалану тәртибе һәм бу резервларның файдаланылган чараларын яңадан торгызу тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

Финанс ресурслары һәм матди ресурслар резервлары, резервларны (резерв фондларын) булдыруның һәм алардан файдалануның әлеге өлешнең икенче абзацында күрсәтелгән тәртибендә каралган очракта, югары әзерлек режимы кертелгәндә файдаланылырга мөмкин.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты федераль һәм регионара характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү очракларында Россия Федерациясе гражданнарына, чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга бер мәртәбә бирелә торган матди ярдәм, финанс ярдәме күрсәтүгә һәм бер мәртәбә бирелә торган пособиеләр түләүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыруга бәйле булган чыгымнарны башкарырга хокуклы. Әлеге максатларга Татарстан Республикасы тарафыннан тотылган чыгымнарны финанс белән тәэмин итү Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә федераль бюджет акчалары исәбеннән тәэмин ителергә мөмкин.

10 статья. **Татарстан Республикасы аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчен югалтуын тану**

Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

1) «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш);

2) «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2006 елның 20 июлендәге 58-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 7 (I өлеш);

3) «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 11);

4) «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 16 маендагы 17-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 5 (I өлеш);

5) «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 19 маендагы 19-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 5);

6) «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы закон актлары аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2012 елның 3 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 3);

7) «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2012 елның 29 сентябрендәге 67-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 9);

8) «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 11 апрелендәге 28-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 4 (I өлеш);

9) «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 7 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 3);

10) «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 12 статьяларына үзгәрешләр

кертү хакында» 2015 елның 6 мартындагы 11-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 3);

11) «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 8 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 10 (I өлеш);

12) «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 7 маендагы 28-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2016, № 5);

13) «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 1 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 19 (I өлеш);

14) «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 25 декабрендәге 110-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2020, № 4 (I өлеш);

15) «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 11 маендагы 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2020, № 37 (I өлеш);

16) «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы закон актлары аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 11 декабрендәге 89-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2021, № 93 (I өлеш);

17) «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 24 мартындагы 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2022, № 24 (I өлеш);

18) «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 9 статьяларына һәм «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы турында» Татарстан Республикасы Законының 7 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 23 декабрендәге 94-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2022, № 96 (I өлеш);

19) «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 6 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2023, № 27 (I өлеш);

20) «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 21 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 29 апрелендәге 21-ТРЗ номерлы Татарстан

Республикасы Законын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2024, № 34 (I өлеш);

21) «Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына һәм «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 17 октябрендәге 85-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2024, № 79 (I өлеш).

11 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2026 ел, 25 июль
№ 43-ТРЗ